СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«01» ноябрь, 2024 ел Алабуга шәһәре № 391

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 23 сентябрендәге 232 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2009 елның 23 сентябрендәге 232 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 нчы статьяда:

1) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Район бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

2) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Районның гавами тыңлауларына чыгарыла торган бюджет проекты Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан агымдагы елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча гавами тыңлаулар билгеләү турында хәбәр белән бер үк вакытта бастырып чыгарыла.».

3) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.Районның гавами тыңлауларына чыгарыла торган бюджет проекты Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан агымдагы елның 1 июненнән дә соңга калмыйча гавами тыңлаулар билгеләү турында хәбәр белән бер үк вакытта бастырып чыгарыла.».

1.2. 12 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне манлау проектлары, аларга үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый актлар проектлары буенча гавами тыңлаулар үткәрү срогы шәһәр халкына аларны үткәрү турында хәбәр иткән көннән алып җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр ундүрт көннән дә ким һәм утыз көннән артып китмәскә тиеш.

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү срогы шәһәр халкына аларны үткәрү турында хәбәр иткән көннән алып җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр бер айдан да артып китмәскә тиеш.

Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү өчен каралган тәртиптә һәм срокларда уздырыла.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов